КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 1 февраль г.Казань № 49

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдыру турында» 2008 ел, 11 июль, 488 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдыру турында» 2008 ел, 11 июль, 488 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 5 май, 296 нчы; 2016 ел, 24 май, 341 нче; 2017 ел, 20 июнь, 398 нче; 2021 ел, 22 июль, 640 нчы; 2021 ел, 6 сентябрь, 825 нче; 2022 ел, 12 гыйнвар, 1 нче; 2022 ел, 14 март, 232 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның икенче абзацында «министрлыкларның һәм ведомстволарның» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары гадәттән тыш хәлләрне бетергәндә кешеләр тормышы һәм сәламәтлеге өчен турыдан-туры куркыныч янауны бетерү буенча һәлакәттән коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкару өчен, зыян күрүче гражданнарны вакытлыча урнаштыру һәм тукландыру пунктларын җәелдерү һәм карап тоту өчен, халыкка бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү өчен, шулай ук зыян күргән халыкның тормыш эшчәнлеген тәэмин итүгә бәйле башка беренчел чаралар өчен кулланыла.

Гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары (дәүләт матди резервыннан тыш) әзерлек югары дәрәҗәдә булу режимы кертелгәндә файдаланылырга мөмкин.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин